Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Түбән Кәминкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге гражданнары җыены карары

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге составына керүче **Түбән Кәминкә** һәм **Кара Чишмә** авылы торак пунктларында

**26 октябрь 2021** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы **Түбән Кәминкә** һәм **Кара Чишмә** авылы торак пунктларында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елда Түбән Кәминкә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш

2.Алынган чараларны җибәрергә:

- **Түбән Кәминкә һәм Кара Чишмә** торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юл-урам челтәрендәге юл кырыйларын норматив хәлгә китерү, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;
- **Түбән Кәминкә һәм Кара Чишмә** торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, торак пунктларда урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- **Түбән Кәминкә** торак пунктында «Урта Чишмә» чишмәсен ремонтлау, **Кара Чишмә** торак пунктында "Кизләү" чишмәсен ремонтлау (чишмә территориясенең санитар-яклау зонасын төзекләндерү, коймаларны ремонтлау һәм буяу, павильон урнаштыру, павильон тышлау, каты өслекле юл урнаштыру, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект-смета документациясе өчен түләү) **Түбән Кәминкә һәм Кара Чишмә** торак пунктларында әлеге эшләрне (хезмәтләр күрсәтүне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу
- авыл җирлеге территориясен төзекләндерү буенча проект-смета документлары өчен түләү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Түбән Кәминкә авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Халиков